СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.03.2018с.Ямбулатово № 36 - 151

«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» Ямбулат авыл җирлеге Советының 2016 елның 09 гыйнварындагы 02-07-02 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Югары Ослан районы прокурорының 09.01.2018 ел № 02-07-02 протестын караганнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымын түләү буенча салым ташламалары бирү турында» Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының 19.09.2017 ел № 30 - 123 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган җир кишәрлекләре (өлешләре) өчен бары тик бер җир кишәрлеге өчен генә бирелә дип билгеләргә»;

1.2. Әлеге карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүче-физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлау буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы»;

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н.Ахметзянов